# ТУГАН ҖИРЕМ ТАТАР БИЗНӘСЕ

## Чүпрәле районының Татар Бизнәсе авылы турында шигырьләр, җырлар

Казан
«Халкыбыз мирасы»
2021

ББК 26,59
УДК 908
Т81

Т81 **Туган җирем Татар Бизнәсе**. Чүпрәле районының Татар Бизнәсе авылы турында шигырьләр, җырларю – Казан: «Халкыбыз мирасы» нәшрияты, 2021. –72 б.

Әлеге җыентык киң катлам милләттәшләребезгә адресланган.

© «Халкыбыз мирасы» нәшрияты, 2021



## БЕЗНЕҢ ТАМЫРЛАР – БИЗНӘДӘ!

Безнең тамырлар – Бизнәдә!–
Бик тә, бик тә тирәндә...
Үтәш биләр, Мәрҗаниләр
Яши кебек тирәмдә.

Алар рухы яши бездә –
Шуңа көләч йөзебез,
Киңдер безнең күңелебез,
Хактыр әйтер сүзебез!

Әткәй-Әнкәйләрдән күчкән
Түземлек һәм Сабырлык,
Тырышлык һәм Максатчанлык... –
Баксаң, хәйран калырлык!

Горур да без, үзсүзле дә,
Вәгъдә биргәч, үтибез!
Сөйгәннәрне кадерлибез,
Яннарыннан китмибез!

Гаилә җылысын саклыйбыз –
Сүндермибез Учакны!
Каршылыйбыз җан дусларны –
Ихлас җәеп кочакны!

Җыр тыңларга яратабыз,
Җырларга да! – хисле без...
Дәвалыйбыз кешеләрне,
Тылсымчыдай көчле без!



...Безнең тамырлар – Бизнәдә!
Изге җирдә – тирәндә...
Үтәш биләр, Мәрҗаниләр
Көч-дәрт бирә тирәмдә!

***Рөстәм Бакиров,***
*2009*



## БАБАМНАР ВАСЫЯТЕ
*(Җыр)*

Нәсел тамырлары бик тирәндә,
Эзләп табыйк – кирәк һәркемгә дә.
Зур шәхесләр чыккан Бизнәбездән,
Хисләр ташый һәркем йөрәгеннән.
Һич тынмасын данлы чор җыры,
Өзелмәсен буын чылбыры!

Шул тылсымлы җырны отып алып,
Күңел түрләренә моңнар салып,
Килен-кияүләр дә була торсын,
Оныклар да күпләп туа торсын.
Юансыннар әби-бабайлар,
Яшәсеннәр безнең балалар!

Сөенерлек булсын һәр эшебез –
Татар Бизнәсеннән чын кеше без!
Васыятьнамә язган бабайларга
Рәхмәт әйтеп яшик һәр заманда.
Һич онытмыйк тарихи үткәнне,
Сокландырып яшик күпләрне!

***Рөстәм Бакиров***





---

*Рөстәм Сәрвәров музыкасына Раиф Мөхәммәтрахимов, Мәкъсуд Юлдашев, Илназ Минвәлиев башкаруларында таныш.

## ИХ, БИЗНӘМ ЯКЛАРЫ!

*Ямьле Бизнә авылында туып үскән хөрмәтле милләттәшләремә багышлыйм*

Бизнә дигән матур авыл –
Безнең авыл була ул.
Тау буенда гөлбакчадай
Нурланып утыра ул.

Халкы аның шундый уңган –
Җырлап бара эшләре.
Эштә, көрәштә чыныгып
Үсә татар яшьләре.

Сагынып кайтам Бизнәмне,
Тугры калып антыма.
Матур ис(е)мен җырга салып
Бүләк итәм халкыма.

Шундый бер ана бар анда –
Исеме тарихка кергән:
Әкият батырлары кебек
Җиде егет үстергән!

Җидесе дә лачын кебек,
Җидесе дә уңганнар.
Көрәштә дә сынатмыйлар,
Эшкә дә булган алар.

Их, Бизнә яклары,
Иң күңелле чаклары.
Сагынышып, куанышып
Кайтадыр кунаклары!



Безнең Бизнә бер генә,
Гүзәллеген күр генә,
Батыр егетләр үстерә
Бизнә кебек ил генә.

Җәйләрнең житүләрен
Сагынып көтүләре,
Их, шул Бизнә урамыннан
Бер җырлап үтүләре!

Сагындым туган авылны,
Кунакка кайтам тагын.
Яшә, Бизнә, гөрләп яшә,
Еракка китсен даның!

***Резеда Вәлиева***



## ТУГАН АВЫЛЫМ КҮҢЕЛЕМДӘ
*(Җыр)*

Авылларның иң матуры –
Минем туган авылым.
Күргән ул үз гомерендә
Тарих җилен, давылын.

*Кушымта*:
Эх, Татар Бизнәсе,
Һәрвакыт күңелдә син.
Кайткан чакта туган йортка
Ерактан күренәсең.

Синең юлларыңнан йөргән
Безнең әти-бабалар,
Тәгәрәшеп синдә үскән
Без бит синең балалар.

Йөрәкләрдән чыкмый бер дә,
Тарта һаман үзенә.
Балачакка кайткан кебек
Булам сиңа үзем дә.

Кунакчыл һәм ачык йөзле
Минем авылдашларым.
Бары Бизнәгә тоташа
Беренче юл башларым.

***Тәлгать Бакиров***

---

*Рөстәм Сәрвәров үз музыкасына башкаруында, Сафуан Хәбиров музыкасына Илнур Баязитов башкаруында таныш.





## ҮТӘШ ЧИШМӘЛӘРЕ
*(Җыр)*

Сагынуга түзеп буламени?
Кайтып барам туган ягыма.
Чал башларым күккә тияр кебек
Менгән чакта Бизнә тавына.

*Кушымта:*
Тирә-якны көмеш чыңга күмеп
Үтәш чишмәләре челтери.
Чишмә суы анам сөте кебек,
Изге моңнар булып, җанга сеңеп,
Безгә бәхет, исәнлек тели.

Монда минем әби-бабаларым,
Дога кылам алар рухына.
Көмеш тәңкә салам, йоласы шул,
Үтәш чишмәләре суына.

Сукмаклардан үтәм яланаяк,
Балачагым йөгерә каршыма.
Бизнәкәем, сагынып кайткан балаң,
Якты йөзең белән каршыла.

***Рөстәм Бакиров***

---

*Зөфәр Хәйретдинов үз музыкасына һәм ИлСаф башкаруында таныш.







* * *

Туган авылым Татар Бизнәм,
Яшисең син йөрәк түрендә.
Сиңа атап бүген жырлар язам,
Оныта алмам сине гомердә.

Шаулап үскән иген басуларың,
Урманнарың һәм дә елга-чишмәң.
Бер жирдә юк андый гүзәллекләр,
Синдә генә бары, Татар Бизнәм.

Авылымнан читтә яшәсәм дә
Күңелем һаман шунда ашкына,
Бала чактагы урамнарым
Йөрәгемдә уелып саклана.

Әткәй-әнкәй, әби-бабай баскан,
Туган авылым, синең жиреңә
Мең еллыкның зур тарихы сыйган,
Татар Бизнәм, синең түреңә.

***Татар Бизнәсе авылында яшәүче ханым***



## БОРМАЛАНЫП БИЗНӘ СУЫ АГА
*(Җыр)*

Үткән белән киләчәкне бәйләп,
Бормаланып, Бизнә суы ага...
Халкыбызның сагыш-шатлыклары,
Күпме тарих, яшәү гаме анда!

*Кушымта:*
Бизнә данлыклы ул илгә-көнгә
Күренекле шәхесләре белән:
Шәйхелислам Садретдинов,
Бакировлары турында
Бөтен дөнья белә.

Тырыш халык яши бу авылда.
Үрнәк игенчеләр бар монда.
Кыр батыры – Калимуллиннар һәм
Көрәш ветераны – Ярулла.

Ил алдына килгән сынаулардан
Бизнә халкы куркып калмаган.
Матур яшәү өчен, туган ил хакына
Сугышларда җиңү яулаган.

Бүген дә әле Бизнә балалары
Төрле бәйгеләрдә ярыша:
“Тамчы-шоу”да җиңү яулый алар,
Сабан туенда бил алыша.

Ил сулышын тоеп яши авыл,
Заман белән бергә атлый ул –
Фән-техника алга киткән чорда
Ватан ышанычын аклый ул.

Үткән белән киләчәкне бәйләп,
Бормаланып, бизнә суы ага.
Батырлыкка, матурлыкка өндәп,
Чакыра ул киләчәккә, алга!

***Гүзәл Таҗетдинова***



———————————————————

*Миңзифа Таҗетдинова музыкасы

## ӘТКӘЙГӘ ХАТ

*(поэма-монолог)*

Бөек Ватан сугышы каһарманы һәм хезмәт батыры булган кадерле Әтиебезгә – «Батырлык өчен», «Ленинград оборонасы өчен», «Берлинны алган өчен» медальләре, Кызыл Йолдыз һәм III дәрәҗә

Дан орденнары кавалеры Сәйфулла Атаулла улы БАКИРОВка.

«Үткәннәргә хатлар бармый, диләр...
Бара алар – туса зур теләк! –
Газиз Әткәң торса күз алдында,
Булып сиңа һәрчак нык терәк!..»

*Шаһинур МОСТАФИН,*
*әзтабар әдип һәм шагыйрь.*

Шагыйрь хаклы: еллар үткән саен,
Якыная безнең аралар!
Синең күзләр, нәкъ элекке кебек,
Сынап һәм яратып багалар...

Сине сагынуларым чиктән ашкач,
Җырга күчердем мин хисләрем!..
...Рәсемеңә карап еш уйланам –
Тынгы таба алмыйм кичләрен...

«Исән чакта, Сине тиешенчә
Кадерләдек микән?» – дип уйлыйм.
Хыялымда һәм өнемдә кайтып,
Туган-үскән җирне еш урыйм!





Искә төшә һаман малайчаклар...
Таулар, су буйлары, таллыклар
Күз алдымда тора гомер буе,
Алар – безнең тиңсез байлыклар!

Искә төшә Сабан туйлары да:
Бил алыштык, мәйдан тоттык без!
Курыкмыйча чыккач көрәшергә,
Тормышта да күпне оттык без!..

Көрәшергә синнән өйрәндек без! –
Гадел, көчле булдың һәр чакта.
...Инде менә хәзер җылынабыз
Син кабызган сүнмәс учакта!

Ул учакны җиде телле, диләр...
Без дә җиде егет – бертуган!..
Һәркайсыбыз, бөркетләргә охшап,
Тормыш киңлегенә омтылган!

Югалмадык гомер юлларында,
Сөйгән ярны таптык һәм эшне...
«Сәйфулланыкылар булдыра!» – дип,
Горурланып әйтте күп кеше...

Әниебез дә шуңа яраткандыр –
Синең өчен торды өзелеп!
Үзең дә бит аны хөрмәт иттең –
Була белдең һәрчак ир-егет!

«Егетлек ул көрәш мәйданында,
Яуда беленә!» – дип сөйлиләр...
Әле һаман орден-медальләрең,
Чыңлап, «Җиңү җыры»н көйлиләр!



«Җиңү таңын тизрәк аттырыйм!» – дип,
Яшьләй ут эченә кергәнсең...
Ләбиб кебек батыр дускаеңның
Вакытсыз үлемен күргәнсең...

Сапер булган Синең ул якташың –
Дошман миналарын юк иткән!
Ә син исә күперләр салгансың –
Җиңүгә юл шуннан да үткән!

Ләбиб дустың һәлак булган көнне
Гел исеңдә тоттың, Әтием...
Уйлангансың: «Ошбу авыр хәлне
Якыннарына ничек әйтием?!»

Алып кайткансың Син туган якка
Шәһит киткәнлеге хәбәрен...
Үз улыңдай сөеп малаен да,
Җиңеләйткәнсең гаилә хәлләрен!

...Инде ул малай да – бабай хәзер:
74 ел үткән сизелми!..
«Ә йөрәктә сагыну ялкыннары
Еллар үткәч тә һич сүрелми», –

Дия безгә Ләбиб батыр улы –
Рафаил абый үзе дә...
Мөлдерәпләр карый бер фотога –
Энҗе бөртекләре күзендә.

Ул фотода Ләбиб батыр белән
Әти, синең дә бар сурәтең...
«Чын дуслыкның нинди булганлыгын
Аңлатты ул безгә, өйрәтте!» –

Диеп, янә Рафаил абый
Кат-кат карый ошбу фотога –
Күңелендәге эч серләрен сөйли
Яудан кайтмый калган атага!

Ә безнеке кайткан – Берлинны алып! –
Дусты өчен дә ул сугышкан:
«Җиңелмәссең, кан эчүче фашист! –
Батырлык хас безгә тумыштан!»

Шулай дигән Атаулла улы –
Сәйфулла ул! – Безнең Әткәбез!..
Еллар аша хөрмәтебез арта,
Зур горурлык белән әйтәбез:

«Чын батыры булган Илемнең!» – дип...
Шигырьләргә керттек исемен!
(Энекешләрем дә шигырь яза –
Исен китәреп һәр кешенең!)

Шул уңайдан, Тәлгать энемнең дә
Шигыреннән алып бер өзек,
Биредә аны язып үтим әле –
Әткәм тыңласын, – дип, – сөенеп!

«Син үзең дә, Әтәй, Җиңү байрагын
Элгән каһарманга тиңдәштер –
Берлин өчен барган сугышларда
Гази Заһитовка иңдәштер!

Син дә күтәрештең ул Байракны,
Кайнар каның тамды аңарга:
Йөрәк яның ядрә тишеп үтте...
Исән калдың!!! Кирәк данларга!..





Егылып калган булсаң чит-ят җирдә –
Без тумаган булыр идек лә...
Син булганга һәм Әнәй булганга –
Бу дөньяга без бит килдек лә!»

Әкияттәге җиде егет кебек,
Сөендереп Әткәй-Әнкәйне
Яшәдек һәм яшибез җирдә!..
Сүздән коеп Сезгә һәйкәлне,

Мең рәхмәтләр әйтәсебез килә –
Сез бит моңа күптән бик лаек:
Безнең замандашлар арасында
Исемегез йөрде макталып!

Гомер юлын намус белән үтеп,
Бакыйлыкка инде күчтегез...
«Сезне уйлап, дога кылып үтә
Фанилыкта иртә-кичебез!» –

Шулай дия Марифә апабыз да –
Сеңелең Синең күпне кичергән...
Хәтер дисбесе гел кулларында,
Һич чыгармый Сине исеннән!

Дәвамчыларың да шактый инде –
Егерме оныгың бар!.. Ходайга
Рәхмәтләр әйтеп яшәсәк гел,
Эшләр барыр, димен, уңайга!..

Әткәй! Синең дустың Ләбибнең дә
Улы сынатмаган тормышта:
Әтисенең рухын зурлаган ул
Һәр адымда, һәрбер сулышта!



Рафаил абый – Зәкия апа белән –
Донбасс төбәгендә эшләгән...
Батыр шахтер булгач, данлы исемен
Яңгыраткан – телдән төшмәгән!

Безнең халыкка бит батырлык хас! –
Яу кырында булсын, хезмәттә...
Шул батырлык күчә каннар аша,
Чын Кеше булырга өйрәтә!

Без дә шулай үстек... Үрнәк булдың
Бар сыйфатың белән тормышта!
Үзеңне Син батырларча тоттың
Алган чакта соңгы сулыш та...

Йөрәк тибешең тоям һаман, Әткәй,
Соңгы тапкыр кулым кысканың...
Шул тибешне һәрчак сизеп торам,
Үтим әманәтең – кушканың!

Ә теләгең изге иде, Әткәй,
Ургып чыкты сүзләр авызыңнан:
«Йөрәгемнең көчен, сүнмәс дәртен
Улларыма күчереп калдырам!

Кирәк булса, аны факел итеп,
Барыр юлыгызда яндырам!!
Оныкларым да аннан дәрман алсын –
Шуны тели минем җан гынам!!!»

Әткәй, күчтең инде йөрәкләргә –
Минем йөрәктә дә шул йөрәк!
Минем йөрәк – Синең йөрәк кебек,
Бергә типкәч – нинди зур терәк!

Шулай дия барлык улларың да,
Киленнәрең дә! – Барысы сагына!
Кызлар, кияүләр һәм оныклар белән
Баш иябез Синең алдында!
Баш иябез Әнкәй алдында!

(Икегез дә безгә бик кадерле,
Икегез дә – йөрәк түрендә!)
Тормыш юлын матур үттегез –
Җәннәттә дә шуңа Сез бергә!!)

* * *

Ләбиб дускаеңның улы белән
Элемтәбез нык, һич тә өзелми! –
Мунчәли һәм Татар Бизнәсендә
Ихлас дуслык хисе сүрелми...

Рафаил ага һәм Зәкия апа
Дүрт балага гомер биргәннәр!
Румил исемлесе һәлак булган
Әфган җирендә... «Тагын тилгәннәр

Очып йөри Донбасс күгендә!» – дип,
Өзгәләнә шахтер үзәге...
Әйтегезче, җирдәшләрем минем,
Сугышның соң бармы кирәге?

Сугышлардан гарык булдык инде...
Күңел тели бары Тынычлык! –
Әтием әйтә кебек еллар аша:
«Шуның өчен дә бит тырыштык!»

...Һич кенә дә тыныч карый алмыйм
Дәһшәтле шул сугыш чорларын.

Күңелемнән ургыла да чыга
Хәтер төпкеленнән җырларым!

Ул җырларда, Әткәй, Синең аваз,
Синең батырлыгың, куәтең!
«Җырлап яшә, улым, тормышта!» – дип,
Яшь чактан ук үзең өйрәттең!

Син башлаган җырны дәвам итәм:
Синең җырың бит ул, Әтием!
Алмаш булып килгән варисларга:
«Синең васыятең!» – дип әйтермен...

***Рөстәм Бакиров, 2015***



## БАТЫРЛАРГА

*(Җыр)*

Яу кырында калган дусларыңны
Чыгармадың, әти, хәтердән...
Батырларга мәңге рәхмәтле без –
Алар илгә җиңү китергән!

*Кушымта:*
Бөек җиңү көнен якынайткан
Курку белмәс батыр солдатлар.
Яралары әрнеп сызласа да,
Утка кыю кергән бит алар.

Тимер ярчык кереп яшеренгән
Баһадирдай көчле гәүдәңә.
Шартлаткыч та сине җиңә алмаган,
Ходай үзе саклап йөргәнгә!

Бәхилләшкән чакта: “Улым” – диеп,
Соңгы тапкыр кыстың кулымны.
Көч-кодрәтең бирдең гомерлеккә,
Җиңеләйттең узар юлыңны.

*Кушымта:*
Бөек җиңү көнен якынайткан
Курку белмәс батыр солдатлар.
Яралары әрнеп сызласа да,
Сер бирмәгән, түзгән бит алар.

__________________________________

*Тәлгать Вәлиев музыкасына Рөстәм Асаев, Рөстәм Насыйбуллин башкаруларында таныш.



Сиңа лаек уңган улларың да,
Туган җиргә тугры һәм тырыш.
Имәндәй нык нәсел тамырыбыз,
Гөрләп тора безнең дә тормыш.

*Кушымта:*
Бөек җиңү көне якынайткан
Курку белмәс батыр солдатлар.
Батыр солдат булып илебезгә
Җиңү яулап кайткан бит алар.
Җиңү яулап кайткан батырлар!

***Рөстәм Бакиров,***
*2015*



* * *

Шаулап чәчәк ата язын
Алмагач чәчәге агачта.
Көнләшеп ак чәчәккә чума
Бәрәңге чәчәге сабакта.

Бер-берсе белән көнләшеп
Алар бер исем алганнар.
Безнең мишәрләр арасында
«Алма» булып калганнар.

Алсу йөзле кызсыман
Алма үзенә сокландыра.
Бәрәңге дә аннан калышмый,
Бөтен бәндәне тукландыра.

Бәрәңге белән ипи дә зур,
Ансыз беркем ашамый.
Өстәлдә алар булмаса,
Беркем көнен башламый.

Бәрәңге ит белән дә зур,
Ашасаң телне йотарсың.
Эчең тулы ризык белән
Кеше кебек йокларсың.

Бәрәңге ул май белән дус,
Бәрәңге пешми ансыз.
Боламыкка май салмасаң,
Ашавы да була җайсыз.

Суганны да ярата ул,
Яшелчәсен, салатын.
Бар да аның дуслары,
Тәмле итеп кабасың.



Бәрәңге күп ашаганга
Тәгәрәп яши халык.
Бер төптән - бер чиләк,
Җирдә ята зур байлык.

Сүзем шул турыда минем
Дусның да дошманы була.
Колорадо коңгызы белән
Бәрәңге җире тула.

Каян килгән бу җәфа
Бакчага зыян сала.
Кеше тырыша-тырмаша,
Эзли анардан чара.

Әй, дусларым-кардәшләрем,
Ашыйк җир алмасын.
Бергәләшеп бәйрәм итик,
Үкенечкә калмасын.

Бар да күркәм, бар да матур,
Җыелганнар уңганнар.
Бәрәңге кебек тәгәрәшеп
Яшик әле, туганнар!



***

Ачы сугыш еллары
Зур яралар калдырды.
Гомерләргә хәсрәт ясап
Йөрәкләрне яндырды.

Язлар җиткәч ач халык
Бәрәңге ындырын казыган.
Тамак туйдырыр өчен
Туң бәрәңге кыздырган.

Әй, тәмле булган да соң
Туң бәрәңге күмәчләре.
Күп халыкны саклап калган
Алабута тәлгәчләре.

***Рауза Айсина,***
*Татар Бизнәсе авылы, 2016*



## БӘРӘҢГЕГӘ МӘДХИЯ
*(Җыр)*

Бәрәңгене, бик яратып,
Икенче икмәк диләр...
Тәмле дә ул, туклыклы да, -
Мактап бер җырлап җибәр!

Кушымта:
Язлар җиткәч бәрәңгене
Утыртабыз кадерләп.
Үзең үстергән бәрәңге
Бар нәрсәдән тәмлерәк.

Яшел була, ямьле була
Бәрәңге сабаклары.
Шул ярмалы бәрәңгенең
Тәмле була ашлары.

Сине зурлап, рәхмәт әйтеп,
Халкым сиңа баш ия.
Бүген бездә зур тантана,
Җырлыйм сиңа мәдхия!
Бәрәңгегә мәдхия!

***Рөстәм Бакиров,***
*2016*

---

*Тәлгать Вәлиев музыкасына Илгиз Шәйхразиев башкаруында таныш.





## ЙОМРЫ БӘРӘҢГЕ

Черек бәрәңгене ашап үскән
Картларыбыз бик аз калдылар,
Кабык чәчеп уңыш өмет иткән
Заманалар артта калдылар.

Коткарган үлемнән, ачлыктан, интеккәннән,
Замананың барча кешесен.
Хәзергәчә бик кадерле булды
Үзебезнең җир бәрәңгесе.

Күпләп чәчтек совет заманында,
Кул хезмәте бик күп кушылды.
Өченче класс мәктәп баласын да
Уңыш җыйганда файдаландык.

Инде заманалар бик-бик рәхәт хәзер,
Трактор чәчә, сыза арасын,
Ә алганда инде трактор сипкән
Бәрәңгене чүпләп аласы.

Йодрыктан да зур уңышы аның,
Шатлык кына барны чүпләргә.
Нинди генә сортлары юк аның
Чит илнеке дә бездә үсә.

Көлдә пешкән йомры бәрәңгене
Сагынабыз әле бүген дә.
Бер генә көн үтми бәрәңгесез,
Ходай аермасын икмәктән.

***Гөлшат Шиһапова,***
*Иске Чүпрәле авылы, 2016*





**БӘРӘҢГЕ ТАКМАКЛАРЫ**

Түзалмадым, түзалмадым,
Гармун алдым кулыма.
Их, әйдә бер җырлыйк әле
Бәрәңгебез турында.

Их, бәрәңге, нишләр идек
Син булмасаң әгәр дә?
Шатлыкта да, кайгыда да
Киләсең бит ярдәмгә.

Булдырабыз, ди Шәймиев,
Йөргән юк артта калып.
Ник әле булдырмаска ди?
Без бәрәңгеле халык!

Бәрәңгеләр үсеп тора,
Атып тора чәчәге.
Күз алларына да килми
Бәрәңгесез яшәве.

Колорадо коңгызларын
Җибәргән Америка.
Ач калсын Рәсәй диядер,
Курка шул бездән, курка.

Америка, колорадо,
Шатланма әле бер дә.
Бәрәңгене гомергә дә
Бирмәбез рәнҗетергә.

Өлгереп җиткән бәрәңге,
Җыябыз да җыябыз.
Нигә матур булмасын ул
Бәрәңгеле дөньябыз?

Әйдә, пешер бәрәңгене,
Син мине дә сыйларсың.
Бөтенесе туйдырса да,
Бәрәңгедән туймассың.

Тәннәреңә куәт бирә,
Кәефләрне күтәрә.
Өстәлләрнең түрендә ул,
Бәйрәмдә дә, эштә дә.

Олы рәхмәтләребезне
Әйтә белик, әйдәле.
Яшә генә, яшә мәңге,
Галиҗәнәп бәрәңге!



## ТУГАН НИГЕЗ

Туган нигез – космодром кебек,
Кайтабыз да аңа, китәбез.
Өзелеп ут йоткан әнкәйләрнең
Чәчкәйләрен ап-ак иткәнбез.

Гомер буе факел кебек янып,
Нур сибәләр газиз аналар.
Шул балкышка гел тартыла күңел,
Аңарда мең шифа, дәва бар.

Туган нигез – космодром кебек.
Әнкәй көтеп торгач, күңелле.
Гел яшәсә иде балкып шулай,
Сөендерсен иде гел безне.
Туган нигез – космодром кебек.

***Шаһинур Мостафин,***
*2017*





* * *

Бизнәләрдән урап килгән җилләр
Тәрәзәмә килеп кагылды:
Озакладың, бер кайтып күр, диеп
Ишегемнән кереп сарылды.

Ташладым да бөтен эшләремне,
Чыгып киттем Бизнә ягына.
Бәгырьләрем өзелеп хискә чумдым –
Авылымны үлеп сагынам.

Һәр ел саен язлар алып килгән
Чәчкәләрен аның яратам.
Шул чәчкәләр хуш исләрен иснәп
Җанымдагы әрнү сагышларны
Акрын, акрын җилгә таратам.

Уйга чумып киттем чишмә якка
Чылтыр суын авыз итим, дип.
Үскән җирнең саф һавасын, моңын
Ничә айлар зарыгып көттем бит.

Тыңладым мин кошлар сайрауларын,
Яшьлек сукмагыннан атладым.
Искә төште шундук уйнап үскән,
Эшләп үскән бала чакларым.

Аклык, сафлык сала күңелемә
Яз китергән ап-ак чәчкәләр.
Күз алдына килә елмаешып
Безнең газиз әткә-әнкәләр.

Авылымны сагынып кайттым һәрчак,
Кендек каны тамган туфракны.
Юксынудан энҗе бөртекләре
Күзләремнән тама шул чакта.

***Флёра Тарханова,***
*2014*



**АВЫЛЫМ САГЫНДЫРА!..**

Биек таудан карап киләм
Авылым урамнарын,
Әле тәгәрмәч басмаган
Яшеллек юрганнарын...

Авылыбыз аркылы
Ага Бизнә елгасы...
Елга суының төбе юк –
Чума урман колгасы!

Авылыбызның төп байлыгы –
Болыннары-кырлары.
Егетләре эштә уңган,
Мәхәббәтле кызлары!

* * *

Сагынам сине, сагынам сине
Сагынам сине, авылым!–
Мин бит синең шунда туган,
Шунда үскән бер улың...

Синдә тудым, синдә үстем,
Синдә алдым аң-белем...
Синдә мин тәпи атладым,
Синдә ачылды телем!

Рәхмәт, авылым, син үстердең!–
Булса да авыр еллар...
Сиңа, авылым, һичбервакыт
Өзелмәс минем юллар!..

***Фәхрислам Тимербулатов,***
*Татар Бизнәсе авылы, 2007*



## ӘЙДӘ, ДУСТЫМ, БИЗНӘГӘ

Әйдә, дустым, Бизнәгә –
Кара балчык измәгә!..
Кара балчыкны сагынам –
Кайталмасам Бизнәгә...

Әйдә, дустым, Бизнәгә –
Ашарбыз җир алмасы!
Җир алмасы – бәрәңгенең
Бик күп, диләр, файдасы...

Әйдә, дустым, Бизнәгә –
Ашарбыз майлы катык!
Ай-йолдызларны карарбыз
Яшел чирәмгә ятып...

Әйдә, дустым, Бизнәгә –
Ашарбыз ачы какы.
Безне монда тартып тора
Туган-үскән җир хакы!..

Ишегалдым саз икән,
Үрдәк белән каз икән.
Үрдәк очты, каз калды,
Рәхәт көннәр аз калды.

Әйдә, дустым, Бизнәгә –
Чишмә суы эчәргә!
Чишмә суы дәрман бирә
Бизнә халкы – мишәргә!

***Фәхрислам Тимербулатов***

---

*Халык көенә Фирдүс Тямаев башкаруында таныш







## БИЗНӘБЕЗ БАТЫРЛАРЫ
*(Җыр)*

Шаулап тора Бизнә ягы,
Матур бүген бигрәк тә.
Егетләрнең асыллары
Җыелганнар көрәшкә.

Кушымта:
Әйдә, әйдә, әйдә, күтәреп сал –
Мәйданнар гөрләп торсын әле!
Бизнәнең чын батырлары шулай
Гел артып торсын әле.

Тирәндә безнең тамырлар,
Онытмабыз аларны.
Ата-бабалардан яшьләргә күчкән
Бил алышу дәрманы.

Дәвамлы варислар булгач
Куәтле безнең халык!
Татар Бизнәсе батырларын чөя,
Яшәсеннәр макталып.

***Рөстәм Бакиров***






---

*Рөстәм Сәрвәров үз музыкасына башкаруында таныш.

**БИЗНӘМ, СИННӘН БИЗМӘМ**
*(Җыр)*

Чүпрәледә бер авыл бар,
Исеме аның Бизнә.
Безнең авыл оҗмахка тиң,
Иң матур төбәк җирдә.

Кушымта:
Бизнәм, Бизнәм!
Синнән бизмәм.
Уемда син кич-иртән.
Нури чишмәсенең суын
Җаныма салып китәм.

Таулары, урманнары юк
Дөньяда дан тотарлык.
Урман асты җиләгеннән
Телләреңне йотарлык.

Кушымта:
Бизнәм, Бизнәм!
Синнән бизмәм.
Уемда син кич-иртән.
Болын җиләкләре тәмен
Мәңге җанымда йөртәм.

Бизнә елгасы талында
Оя корган сандугач.
Сандугачлар булып сайрыйм,
Авылым, сине сагынгач.

Кушымта:
Бизнәм, Бизнәм!
Синнән бизмәм.
Уемда син кич-иртән.
Сандугачлар тиздән кайтмас,
Мин кайтырмын дип китәм.

Чит җирләрдә йөргәннәр дә
Сагынып монда кайта
Балачактан безнең җаннар
Бәйләнгән туган якка.

Кушымта:
Бизнәм, Бизнәм!
«Авылым» дип,
Исемеңне җырга салам.
Кайда торсам, кем булсам да,
Мин синең газиз балаң.

***Шәмсия Җиһангирова***



---
*Мирсәет Сөнгатуллин үз музыкасына башкаруында таныш.

## АВЫЛЫМ ТАТАР БИЗНӘСЕ
*(Җыр)*

Язлар житсә, күңелкәем
Туган якларга тарта.
Очар кошларга ияреп,
Җаным да шунда кайта.

Кушымта:
Авылым Татар Бизнәсе,
Уңган апа, жизнәсе.
Чәйләр куеп, каршы ала
Бизнәнең һәр җиңгәсе.

Авылымның биек таулары
Ерактан тора күтеп.
Юллардан күз алалмаган
Әткәй-әнкәем кебек.

Татар Бизнәсенә кайтам
Әле менә бүген дә.
Авылдашларымны күреп,
Дәрт аламын күңелгә.

***Равил Бакиров***

---

*Нәжип Бәдретдинов музыкасына Рөстәм Сәрвәров белән ИлЗилә башкаруларында таныш.








**ТУГАН ЯГЫМ БИЗНӘМ**

*(Җыр)*

Туган җирен бар да сөя,
Миңа Бизнәем якын.
Туган авылым искә төшсә,
Йөрәктә яна ялкын.

Кушымта:
Әй, Бизнәм, Бизнәм, Бизнәем,
Кайтырмын сиңа тиздән.
Кайтырмын сиңа, кайтырмын,
Сагынуларга түзмәм.

Биек таулар саклый сине
Җилләрдән, давыллардан.
Гүзәллегеңаерып тора
Сине чит авыллардан.

Онытмагыз, кайтыгыз сез
Бизнәгә, авылдашлар.
??? саф һавасы,
Чишмәдә чуер ташлар.

Әй, Бизнәм, Бизнәм, Бизнәем,
Кайтырбыз сиңа тиздән.
Сәламнәр булып яңгырасын
Бу җырлар сиңа бездән.

***Рифкать Бакиров***

———————————————————————————

*Рафыйк Таҗетдинов үз музыкасына башкаруында таныш.





**ТАБИБЛАРЛАРГА**
*(Җыр)*

Сәгать түгел, минут хәл иткәндә
Сират күпереннән үтәбез.
Яшәү белән үлем тартышканда
Табиблардан ярдәм көтәбез.

Кушымта:
Ак канатлы фәрештәләр күктә,
Җирдәгеләр ап-ак халаттан.
Гомерөстәр дәвачылар итеп
Табибларны Ходай яраткан.

Гиппократ антына тугъры калып,
Вакытында килеп ярдәмгә,
Якты өмет җебен ялгый табиб
Әҗәл кулындагы адәмгә.

Аяусыз үлемгә баш имичә,
Яшәү өчен көрәш барганда,
Чын батырлык эшли һәрбер табиб
Әҗәл угын тартып алганда.

***Рөстәм Бакиров***

---

*Оскар Усманов музыкасына Сәгыйть Гыйбашев башкаруында таныш.







**АК ХАЛАТЛЫ ФӘРЕШТӘЛӘР**

*(Җыр)*

Гомерләрне мизгел хәл иткәндә
Сират күперләре кичәбез.
Үлем белән яшәү арасында
Сез, табиблар, ярдәм итәсез.

*Кушымта:*
Ак канатлы фәрештәләр оча,
Ак халатлы фәрештәләр була.
Безне саклар өчен табибларга
Кодрәтеңне бирче, я, Хода!

Үзе биргән антка тугры калып,
Авыр чакта килеп яныңа
Гомер җебен кабат ялгап куя
Җибәрмичә күкләр катына.

Әҗәл фәрештәгә баш имичә,
Яшәү өчен көрәш барганда
Зур батырлык кыла һәрбер табиб,
Аллаһы ярдәм итсен аларга.

***Рөстәм Бакиров***

---

*Айдар Фәйзрахманов музыкасына Айгөл Хәйри башкаруында таныш.





* * *

Күл урамы, күл урамы,
Күл урамы – киң урам...
Күл урамы, күл урамы –
Бульварларга тиң урам!

Күл урамы, күл урамы –
Яшел мәчет урамы.
Яшел мәчет урамында
Яңгырый азан моңнары!

Күл урамы, киң булса да,
Озын түгел әллә ни.
Монда булган, дога кылган
Шиһабетдин Мәрҗани.

Күл урамының күлләре
Кибәләр җәйләр җиткәч...
Күл урамы сагындыра
Авылдан чыгып киткәч!

***

Бизнә суы сай булса да,
Еракларга китә ул.
Сура суына кушылып,
Ак Иделгә җитә ул!

***Фәхрислам Тимербулатов***





## БИЗНӘДӘ СУЛАР АГА

*(Җыр)*

Җырга күчкән таулары бар
Туган ягым Бизнәнең;
Күңелем гел шунда тарта –
Матурлыктан бизмәдем.

Җәйләр җитсә, балык уйный
Суларында Бизнәнең.
Сабый чагымны сагынып
Кайттым, күңелем түзмәде.

Кош авазы әрәмәле
Ярларында Бизнәнең –
Моңга чумган шул ярлардан
Яшьлегемне күзләдем...

Яшьлек үтте, аккан судай
Яры буйлап Бизнәнең.
Әй бу гомер агышлары –
Үткәнен һич сизмәдем.

Тәүге сөю эзләре бар
Ярларында Бизнәнең.
Таллар – шаһит, тыңладылар
Сөю сере сүзләрен.

Гомер үтә, сулар ага
Ярын тутырып Бизнәнең.
Күңелләрдә кошлар моңы.
Җанда яшьлек эзләре.

***Рафаил Сиражи,***
*2000*





## КИТМӘМ, БИЗНӘМ
*(Җыр)*

Су буенда таныш таллар һаман
Саклый безнең яшьлек серләрен.
Ничәнче кат инде кичерәм мин
Аерылышуның ачы хисләрен.

*Кушымта:*
Кара туфрагында ералдык та,
Ак бәхетләр эзләп киттек без.
Таралсак та төрле тарафларга,
Синдә яши безнең күңелебез.
Менә тагын озын юллар дәшә,
Яулык болгый Бизнә кызлары.
Сагышлана йөрәк шул чагында
Һәм нечкәрә күңел кыллары.

Менә тагын озын юллар дәшә,
Яшел мәчет бирә фатыйха.
Китеп бара Үтәш оныклары
Сиңа кабат сагынып кайтырга.

Җәйрәп ята икмәк тәме килгән
Гәрәбәдәй иген кырлары.
Тагын кайт, дип озатып калырлар
Бизнә тургаеның җырлары.

***Рөстәм Бакиров***

---

*Шамиль Тимербулатов музыкасына Айдар Фәйзрахманов, Айрат Җамалетдинов башкаруларында таныш.





## КИЛЕГЕЗ БЕЗНЕҢ БИЗНӘГӘ!..

Кайларда гына булсам да,
Авылым миңа якын! –
Урман-кырлар, чишмә-сулар
Сөендерә эшчән халкын...

Чыгып баскач өй каршына,
Хисләнәм дә тик торам:
Изге йортыбыз – мәчеткә
Сокланам да тын калам!...

Авылыбызны матурлап,
Бик шәп мәктәп салдылар! –
Яше-карты, шатланышып
Иркен сулыш алдылар...

Бизнәмдә зур үзгәрешләр –
Ямьләнә ул һәр көнне! –
Ав(ы)лымны күреп китәргә
Чакырам мин һәркемне...

Килегез безнең Бизнәгә –
Тигез хәзер юллары!–
Күңелегездә челтерәр
Чишмәләрнең җырлары...

Килегез безнең Бизнәгә –
Сөенер күңелегез!
Шатлыгыбыз уртак булыр –
Балкып торыр йөзегез!..

***Фаил Бәхтиев,***
*Татар Бизнәсе авылы*





Максатыбыз безнең – изге, матур!
Авылдашлар – уңган, тырыш, батыр!
«Яшәтербез һәрчак Бизнәне,
Яшәртербез!!!» – һәркем теләге...

***Рөстәм Бакиров***




















